**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3419**
**04.07.2019**

«Төзүчеләр көне» шәһәр бәйрәмен үткәрү көнендә Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертү турында

Яр Чаллы шәһәрендә «Төзүчеләр көне» шәһәр бәйрәме үткәрелү уңаеннан, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатында, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары турында һәм юллар эшчәнлеге хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ санлы Федераль законның 30 маддәсе, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында автомобиль юллары турында һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ санлы Законының 27 маддәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 нче карары белән расланган Региональ яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибе , шәһәр Уставының 41 маддәсе 9 пунктының 24.1 пунктчасы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. 2019 елның 10 августында 15:00 сәгатьтән 22:10 сәгатькә кадәр ике юнәлештә дә Хәсән Туфан проспекты буенча Чулман проспектыннан Раскольников урамына кадәр һәм Раскольников урамы буенча Рәис Беляев проспекты белән кисешкән урынга кадәр автомобиль юлы участогында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә.

2. Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсенә чара үткәрү көнендә гражданнар иминлеген, җәмәгать тәртибен һәм юл хәрәкәтен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

3. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм әлеге карарны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл

хуҗалыгы министрлыгының һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтларында урнаштыру юлы белән транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертү турында Яр Чаллы шәһәренең җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан файдаланучыларга хәбәр итүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин